ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 28 мартында
кабул ителде

**1 статья**

Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2, № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 3, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 10 (II өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 8 (I өлеш), № 10 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2012, № 1, № 6 (I өлеш), № 7 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2013, № 1, № 2 (I өлеш), № 6 (II өлеш), № 7, № 10; 2014, № 1 – 2, № 5, № 6 (I өлеш), № 7; 2015, № 3, № 4, № 12 (I өлеш); 2016, № 5, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 33 (I өлеш), № 55 (I өлеш), № 85 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2020, № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2022, № 49 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш); 2024, № 56 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2025, № 1 (I өлеш), № 18 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлектә:

а) исемне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 бүлек. **Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау, төзекләндерү, җәмәгать тәртибен саклау, йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт һәм су объектларында кешеләрнең гомерен саклау өлкәсендә административ хокук бозулар**»;

б) түбәндәге эчтәлекле 3.18 статья өстәргә:

«3.18 статья. **Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга карата өстәмә таләпләрне бозу**

1. Йорт хайваннарын күпфатирлы йортларның гомуми файдалану урыннарында һәм йорт янындагы территорияләрендә тоткан өчен –

кисәтү ясала яисә ике мең сумнан алып дүрт мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

2. Эт хуҗасы тарафыннан этне мәҗбүри теркәүне башкармаган өчен –

кисәтү ясала яисә ике мең сумнан алып дүрт мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган гамәлләрне ел дәвамында кабат кылган өчен –

биш мең сум күләмендә административ штраф салына.»;

2) 7 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 7.10 статья өстәргә:

«7.10 статья. **Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең хайваннарга карата мөнәсәбәт өлкәсендә региональ дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органы әлеге Кодексның 3.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы эшләрне карый.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән орган исеменнән административ хокук бозулар турындагы эшләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы, аның урынбасары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлекләре башлыклары карый.»;

3) 8.1 статьяда:

а) 1 өлештә «7.9» саннарыннан соң «, 7.10» саннарын өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $11^3$ өлеш өстәргә:

«$11^3$. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган очраклардан тыш, әлеге Кодексның 3.18 статьясында каралган административ хокук бозулар турындагы беркетмәләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсенең территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлекләре консультантлары төзи.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2025 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 10 апрель
№ 16-ТРЗ